УДК 821.512.145

*З.Г. Мөхәммәтшин*

# ШӘРКЫЯТЬЧЕ ГАЛИМ ҮРЛӘРЕ

*(С. Гыйләҗетдиневкә –70)*

Салим Гилязутдинов долгие годы работал в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ сначала в отделе народного творчества, затем в отделе рукописей и текстологии. Статья посвящена 70-летию этого прекрасного знатока восточных языков, специалиста по истории ислама и просто хорошего человека.

**Ключевые слова:** Салим Гилязутдинов, татарское востоковедение, арабские и персидские рукописи в фондах Центра письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

Татар халкының мәдәни һәм әдәби багланышы Шәрык мәдәнияте һәм ислам фәлсәфәсенә бәйле. Бигрәк тә Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүе белән аның тәэсире нык арта, хәтта милләтнең милли үзаңы, психологиясе, дөньяга фәлсәфи карашлары да Шәрык стилендә формалаша. Рус дәүләтенең милли һәм дини изүе дә, коммунистик һәм бүгенге Россиянең христианлыкка тарткан идеологиясе дә аны җимерә алмый. Монда халыкның ислам фәлсәфәсенә өстенлек бирүенең һәм Шәрык, шул исәптән татар дин галимнәренең тирән белемле булулары, борынгы традицияләрне саклаган хәлдә мөселманлык идеяләрен сеңдерә белү алымнарының да тәэсире булмыйча калмагандыр. 1917 елгы Октябрь түнтәрешенә кадәр татар галимнәре, беренчедән, дин галимнәре буларак танылсалар, икенчедән, Шәрыкка гына хас фәлсәфи фикерләрне пропагандалаучылар гына түгел, шуның нигезендә, татар халкының милли хисләрен саклап калган бөек шәхесләр дә иде. Шуны да искәртеп үтү урынлы булыр, дини тәгълимат, нигездә, гарәп теле аша өйрәнелсә, Шәрыкның бөек әдәби мирасы һәм аралашу теле фарсы теле икәнлеген дә ассызыклап үтү кирәктер. Кызганыч, инде бүген бай тарихлы Шәрык мәдәниятен, аның әдәбиятын бөтен нечкәлекләре белән белүчеләр бик сирәк, бәлки юк дәрәҗәсендә дип әйтү дөресрәктер дә. Шул сирәкләр арасында гарәп, фарсы, инглиз, рус һәм татар телләрен, аларның мәдәниятен, әдәбиятын камил белгән Сәлим Гыйләҗетдинов турында аерым тукталып, аның фәнни эшчәнлеге, Шәрыкны өйрәнүгә керткән хезмәте хакында фикерләремне белдереп китү урынлы булыр кебек.

Сәлим Минһаҗ улы Гыйләҗетдиновның фәнгә килү һәм уңышларга ирешү юлы гаять тә бормалы һәм дә сикәлтәле. Ул 1947 елның 18 августында әле 40–60 нчы елларда да миллилекне саклап кала алган Ка-

зан шәһәренең Иске Бистәсендә эшче гаиләсендә дөньяга килә. XX гасыр башында Иске һәм Яңа Бистәдә Шәрык стилендә формалашкан мәдәни һәм милли мохитнең уңай традицияләре киләчәктә галим буларак танылачак С. Гыйләҗетдиновка да тәэсир итмичә калмагандыр. Әмма аңа үз теләгенә ирешү юлында шактый каршылыклы юллар узарга туры килә әле. Аның тәрҗемәи хәлен күзәткәндә гомер юлы тоташ каршылыклар белән бара сыман. 1965 елда Казанның 80 нче татар мәктәбен тәмамлаганнан соң, башта берничә ай М. Вахитов исемендәге химия комбинатында, соңрак моторлар төзү заводында фрезерчы булып эшли. Телләр үзләштерүгә сәләте ташып торуга карамастан, заманына хас булганча, төгәл фәннәргә өстенлек биреп, Сәлим, ялгышлык белән генә Казан авиация институтының радиотехника факультетына кичке бүлеккә укырга керә һәм үз һөнәре түгеллеген аңлагач, ел ярымнан укуын ташлый. 1967–1970 елларда Тын океан флотында гидроакустик буларак хезмәт итә. Яхшы хезмәт иткәне өчен Казанга ялга кайта. Мәктәптә гарәп теленә, гомумән, Шәрык мәдәниятенә мәхәббәт уяткан Мәхмүт ага Рәхимовның хәлен белергә баргач, аңа үзенең киләчәк язмышын гарәп телен, Коръәнне өйрәнүгә багышлау теләген җиткерә. Остаз гарәп теле буенча СССРда Мәскәү, Ташкент, Ленинградта уку йортлары барлыгын әйтә. Сәлим әфәнде бу очрашудан рухланып, кабат хезмәткә киткәндә гарәп теле дәреслеге, сүзлекләре алып юлга чыга. Вахтадан бушаган араларда гарәп телен өйрәнә, корабльдә җәмәгать эшләренә актив катнаша, коммунистлар фиркасына әгъзалыкка кандидат итеп тәкъдим ителә. Флот хезмәтенә өч елын багышлаган Сәлим Минһаҗ улы, армиядән кайту белән укырга китә дисәк дөреслеккә туры килмәс, ул башта 1972 елга кадәр радиокомпонетлар заводында (халык телендә җиденче завод) радиокөйләүче булып эшли. Шул елда Ленинград университетына барып имтихан тапшырып карый. Сынау бирүдә катнашса да, уңышсызлыкка очрый. Очраклы гына университет каршында эшләгән рабфакта әзерлек курслары барлыгын белә һәм шул курска укырга керергә тели. Әмма завод директоры Сәлимне эштән җибәрергә теләмичә, нинди генә үгет-нәсыйхәтләр бирми. Гарәп теле буенча югары белем алуга омтылыш зур булган яшь егетне мондый гына каршылыклар сындыра алмый әлбәттә, ул, тәвәккәлләп, Ленинградка китә. Рабфакта инглиз теленнән башлангыч белеме дә булмаган Сәлим әфәнде берничә ай эчендә курсташларын да узып, телне камил дәрәҗәдә үзләштереп, 1973 елда университетның Көнчыгыш телләр факультетына студент буларак кабул ителә.

Бу урында аның остазларын да искә алып үтү урынлы булыр мөгаен. Ул аларга бүген дә рәхмәтле һәм һәрвакыт ихтирам белән искә ала. Ихтирамга лаек остазлар кемнәр дисәгез, менә алар: Татарстанның Апас районы Морзалар авылыннан

чыккан галим Габдерахман Таһирҗанов һәм Ольга Борисовна Фролова, Илья Павлович Петрушевсий, Олег Федорович Акимушкин, Александр Николаевич Болдыревлар.

Шул рәвешле, Шәрык дөньясына танылган шәхесләрдән белем алган Сәлим әфәнде 1978 елда, Ленинград университетының «Көнчыгышның чит илләрен, Көнчыгышны өйрәнүче, Иран тарихчысы» дигән белгечлек буенча укуын уңышлы тәмамлап, Казанга кайта. Күпкырлы Шәрык белгечен, Коръәнне яттан белгән Сәлимне Казан колач җәеп каршы алырга ашыкмый. Шәһәр буенча дүрт ай эш эзләп йөргәннән соң, ниһаять, татар гуманитар фәненең үзәге – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә урнаша. Университетта алган белгечлеге буенча эш булмаса да, халык иҗаты бүлегенә кабул ителгән фәнни хезмәткәр фән үрләрендә беренче чыныгуларын ала башлый. Институтның халык иҗаты бүлеге «Татар халык иҗаты»ның 12 томлыгын әзерли башлаган еллар бу. Сәлим Минһаҗ улына катлаулы томнарның берсе «Риваятьләр һәм легендалар» томын төзү бурычы йөкләнә. Үзен тырыш, эшчән һәм тирән белемле, яхшы әзерлекле итеп таныткан Шәрык телләре белгече буларак, аңа борынгы чыганаклар белән бәйле әлеге томны югары кимәлгә җиткерү өчен шактый нык казынырга, дөресрәге яңа фәнни юнәлеш буенча белем эстәргә туры килә. Ул төзеп бастырган «Риваятьләр һәм легендалар» томының күп өлешен төрки һәм татар тарихына бәйле хезмәтләрдән алынган кыйммәтле чыганаклар тәшкил итә дә инде. Аларның кайберләре XXI гасыр башында «Имам» нәшриятында аерым китаплар булып нәшер ителделәр. Һәм соңрак текстлары кабат каралып, төзәтелеп (борынгы һәм хәзерге татар телендә) 2011 елда Татарстан китап нәшриятында «Мирастан биш сәхифә» исемле китап дөнья күрде. Шулар нигезендә, Болгар һәм Казан тарихына карата халык арасында киң таралган легенда һәм риваятьләрне туплап, татар, рус, инглиз һәм фарсы телләрендә «Казан турында легендалар», «Серле Казан» һәм «Легендалар һәм мифологик хикәятләр» исемле китаплар басылып чыкты.

Институтта Сәлим әфәндегә үз белгечлеге буенча фәкать 1991 елда гына эш тәкъдим ителә. Монда институтны гаепләү урынсыз кебек. Совет идеологиясе хакимлек иткән елларда Казанда гарәп-фарсы чыганакларын өйрәнүгә әллә ни игътибар бирелмәде дә кебек, хәтта, аспирантурада Шәрык телләреннән имтихан бирү өчен шактый катлаулы юллар үтәргә кирәк иде. Кыскасы, зур тәҗрибә туплаган галим институтның кулъязмалар һәм текстология бүлегенә эшкә күчерелә һәм аңа мирасханәдә сакланган фарсы телле кулъязмаларның тасвирламасын эшләү бурычы куела. Галим берничә ел дәвамында өч чыгарылыштан торган, гомуми күләме 46 табак тәшкил иткән хезмәттә, XI гасырдан алып – XX гасырга кадәр татар халкына мәгълүм фарсы телендәге рухи язма байлык-

ны тасвирлап милләтнең белем дәрәҗәсен күрсәтүгә ирешә. (*Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилище института Языка, литературы и искусства. Выпуск I, II, III. Казань: Фикер, 2002, 2006, 2008). Сәлим әфәнде тарафыннан эшләнгән бу китаплар татар гуманитар фәнендә фундаменталь хезмәтләр итеп каралырга лаек.

Күпкырлы галим татар укучысына тәрҗемәче буларак та мәгълүм. Институтта эшләү дәверендә һәм аннан соң да гарәп, фарсы, төрек телләреннән күп кенә әсәрләрне тәрҗемә итеп бастырды. Мәсәлән, төрек галиме Гариф Бикнең «Мең дә бер хәдис шәрехе» дигән төрек телендәге китабын, беренчеләрдән булып, татар мәгърифәтчесе Габдерәшит Ибраһимов татар теленә тәрҗемә итеп, үзеннән өстәмә шәрехләр биреп бастыра. Сәлим әфәнде исә, хәдисләрнең шәрехләрен иске татар теленнән, ә хәдисләрне турыдан-туры гарәп теленнән тәрҗемә итә (*Гариф Бик.* Мең дә бер хәдис шәрехе. Казан: Раннур, 2005). Сәлим әфәнде Татарстан Яңа Гасыр телевидениесе җитәкчелегенең үтенече буенча Иран кино сәнгате осталарының «Шәһрияр» дигән 17 серияле фильмының татарчага тәрҗемәсен дә эшли. Әлеге сериалдагы 84 газәл татарча милли аһәңдә яңгырашы һәм камиллеге белән тамашачының күңеленә һуш килгәндер мөгаен.

Институт һәр җәй илнең төрле төбәкләренә таралып яшәгән татар халкы арасына фәнни экспедицияләр оештыра. С. Гыйләҗетдинов халык иҗаты, кулъязма һәм текстология бүлекләрендә эшләгәндә дә милләтнең асыл җәүһәрләрен җыюда актив катнашты. Ерак Себер, Башкортстан, Киров, Пермь, Рязань, Төмән, Чиләбе, Екатеринбург, Әстерхан, шулай ук Россиянең башка өлкә, край һәм республикаларына, шул исәптән Татарстанның күпчелек районнарына оештырылган фольклор, археографик экспедицияләр вакытында татар гуманитар фәннәре өчен аеруча кыйммәтле тарихи, мәдәни чыганаклар табып, аларны фәнни яктан эшкәртүче, кайберләрен беренчеләрдән булып фәнни әйләнешкә кертүче дә ул иде. XX гасырның 90 нчы елларында Институтта эшләү дәверендә Татарстан Мәдәният министрлыгы каршында оештырылган Фольклор үзәгендә өлкән фәнни хезмәткәр вазыйфаларын башкарды һәм анда да экспедицияләргә чыгып, тарихыбыз, гореф-гадәтләребез, халык иҗаты, сәнгатебез, этнографиябез, гомумән татар энциклопедиясе өчен кыйммәтле, тарихи яктан әһәмиятле булган эшләр башкарды, шул материаллар нигезендә махсус фәнни фильмотека булдыру эшен дә алып бара.

Галим бары академик фән белән генә шөгыльләнде дисәк хакыйкатькә хилафлык килер төсле. Ул дәүләттә башланган үзгәртеп кору елларыннан ук, аерым алганда, 1986 елдан башлап, тирән белемен укучыларга бүләк итүче талантлы педагог буларак та танылa. С. Гыйләҗетдинов педагогик эшчәнлеген Казан шәһәре мәктәпләрендә гарәп теле укытучысы буларак башлап

җибәрә, соңрак Казан дәүләт педагогия колледжында гарәп теле, Казан дәүләт университетында фарсы теле укыта. Болардан тыш милләтнең дини хисләре кабат уянган елларда Коръән өйрәтү курсларында «Тәҗвид», ягъни Коръәнне дөрес уку фәне буенча дәресләр бирә. Ул һәрбер укучы яисә шәкертнең яраткан остазы була. Алар арасында хәрбиләр, дин әһелләре һәм башка күп төрле һөнәр ияләре бар.

Сәлим әфәнденең ислам дине тарихы, аның фәлсәфәсе буенча киң карашлы галим булуына һәм Коръәнне яттан белүенә аерым тукталып үтү кирәктер. Студент елларында ук Коръән сүзләрен картотекага сала башлаган галим бүген Коръән сүзләре күрсәткечен төзү белән мәшгуль. Инде бу күрсәткеч халыкка тәкъдим итү алдында дип әйтерлек. Шулай ук институтта эшләгән елларында аның тарафыннан институт мирасханәсендә сакланган кульязма Коръән тасвирламасы төзелеп, 2013 елда «Описание рукописей Корана» исеме белән нәшер ителде. Бу темага кагылганмын икән, азрак лирик чигенеш ясап алу да комачау итмәс мөгаен. Текстология белән шөгыльләнгәндә, XX гасыр башында иҗат иткән әдипләрнең иҗатларында Коръәннән аятьләр, Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләре, яисә башка гыйбарәләр шактый очрый. Бу өлкәне җитәрлек белмәү нәтиҗәсендә без еш кына төртелеп калабыз. Шул вакыт, һәрдаим ярдәменнән ташламаган, белемгә омтылган яшьләргә һәрвакыт хәерхаһлы булган галим аятьнең кайсы сүрәдән булуын һәм тиз генә тәрҗемәсен, аның мәгънәсен, тарихи темага караганрак булса, тарихын да аңлатып бирә. Хәдисләр белән дә шул ук хәл була торган иде. Киң карашлы, эрудицияле Сәлим әфәнде шушы яклары белән дә сокландыра.

Фән дөньясында галимнең гыйльми дәрәҗәсе аның халыкара конференцияләрдә, конгрессларда, халык каршында ни дәрәҗәдә катнашуына карап та бәяләнә. Шуны да ассызыклау кирәк, Сәлим әфәнде халыкара симпозиумнарда, конференцияләрдә, конгрессларда катнашып, үзен чын галим итеп таныта алды. Ул 1994 елда Иранда булып узган фарсы теле, Иран тарихы һәм ислам белгечләренең I Халыкара конгрессында катнашты. Анда ул Иран президенты тарафыннан оештырылган кабул итү мәҗлесендә була. 2000 елда Сәлим әфәндегә Казанда узган «Иран һәм Россия» дигән халыкара фәнни конференциядә, 2001 елда исә Иранда узган «Иран һәм Туран» исемле халыкара фәнни конгресста да чыгыш ясау бәхете татый. Фарсы темасына кергәнмен икән, Сәлим әфәнде бу өлкәдә дә шәкерт тәрбияләгән галим.

С. Гыйләҗетдиновның фәнни казанышлары болар белән генә чикләнми әлбәттә. Аның 2011 елда фарсы-татар әдәби бәйләнешләре буенча «Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX вв)» монографик хезмәте дә дөнья күрде. Махсус әзерлекле Шәрык телләре белгече, тәрҗемәче, сәяхәтче, педагог, киңкырлы талант иясе Сәлим әфәнденең институтта һәм инсти-

туттан тыш 40 ел чамасы фәнни эшчәнлеге дәверендә бүген дә, киләчәктә дә әһәмиятен югалтмаячак 22 китабы, күпсанлы фәнни мәкаләләре басылып чыккан.

Мәкаләнең башында ук Сәлим әфәнденең тормыш баскычлары каршылыклар һәм көрәшләрдән торуы искәртелгән иде. Ул инде үзен күптән күпкырлы галим итеп танытса да, фәкать озак еллардан соң (22 ел вакыт үткән) 2000 елда гына, Х. Мәхмүтев җитәкчелегендә «Татар тарихи риваятьләре һәм легендалары» исемле темага кандидатлык диссертациясе яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә. Докторлык темасы буенча монографиясе басылып чыгуга карамастан, яклауны ашыктырмый. Хәер, кем әйтмешли, чын галим булу өчен доктор булу мәҗбүри дә түгел анысы. Гомерен фәнгә багышлаган Сәлим Минһаҗ улы аңа мохтаҗ да түгел. Ул фән докторлары на тиң дәрәҗәдә фәнни-аналитик фикергә ия шәхес. Шәрык мәдәнияте һәм ислам дине тарихы, яисә гарәп-фарсы тәрҗемәләре буенча мөрәҗәгать иткән фән докторларына да галим ярдәм кулын сузарга һәрвакыт әзер.

Озын сүзнең кыскасы, тормыш каршылыкларын җиңәҗиңә ихлас күңелле, олы җанлы, һәркемгә игътибарлы һәм ихтирамлы, авыр хәлләрдә бервакытта ярдәменнән ташламаган галим, педагог, Шәрык телләре белгече, тәрҗемәче, изге вә эчкерсез, саф күңелле Сәлим Минһаҗ улы Гыйләҗетдиновның гомер бәйрәмендә исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, фәнни эзләнүләр юлында тагын да зуррак ачышларга һәм дә уңышларга ирешүен теләп калам. Сәлим әфәнденең андый мөмкинчелекләре бар, әле дары мичкәсендә ялкынлы ут сүнмәгән.

***Мөхәммәтшин Зөфәр Гомәр улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*